ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.02.2021 г. Заинск № 61

**"Муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә социаль ярдәм чаралары турында" 2006 елның 19 декабрендәге 1642 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Авыл җирлекләрендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү максатларында, “Авыл җирендә, эшчеләр бистәләрендә (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында” 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегиясе беркетмәсе нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. "Муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә социаль ярдәм чаралары турында" 2006 елның 19 декабрендәге 1642 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Авыл җирендә яшәүче мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсе муниципаль учреждениеләре белгечләренә, шул исәптән 60 һәм 55 яшькә җитеп пенсиягә чыккан гражданнарга (ир-атлар һәм хатын-кызлар), шулай ук 2018 елның 31 декабренә торышы буенча "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында", "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" һәм "Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында" федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килгән, әмма 60 һәм 55 яшькә җитмәгән (ир-атлар һәм хатын-кызлар) авыл җирендә яшәүче һәм Татарстан

Республикасы Зәй муниципаль районы мәдәният учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгән хезмәткәрләргә торак мәйданының Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль нормасы һәм коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары чикләрендә, торак, җылылык, ут өчен түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә субсидияләр рәвешендә социаль ярдәм чаралары бирүне билгеләргә;»

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктны өстәргә: "Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затларга ярдәм чараларын алу максатларында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә бирергә кирәк".

2. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А. В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма**
**комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Р.Н. Камалова
70782